КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 11 декабрь г.Казань № 967

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 декабрь, 1063 нче; 2015 ел, 8 май, 333 нче; 2015 ел, 17 июнь, 444 нче; 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы; 2016 ел, 30 март, 181 нче; 2016 ел, 25 май, 349 нчы; 2016 ел, 13 сентябрь, 640 нчы; 2016 ел, 21 сентябрь, 670 нче; 2016 ел, 28 ноябрь, 877 нче; 2017 ел, 25 гыйнвар, 29 нчы; 2017 ел, 28 апрель, 254 нче; 2017 ел, 26 июнь, 430 нчы; 2017 ел, 12 август, 568 нче; 2017 ел, 6 октябрь, 766 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2014 – 2025 елларга мәктәпкәчә белем бирүне, инклюзив белем бирүне кертеп, үстерү һәм бу өлкә хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында:

1 бүлекнең егерме бишенче абзацында «(Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2010 ел, 24 март, 209 нчы боерыгы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 бүлектә:

9 пунктның дүртенче абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан гомуми белем бирү учреждениеләре укытучыларына ипотека кредиты бирү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү һәм бүлү тәртибе турында» 2011 ел, 29 декабрь, 1177 нче карары (2012 ел, 16 апрель редакциясендә) белән һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

17 пунктның унбишенче абзацында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2011-2015 елларга «Уңайлы мохит» Татарстан Республикасы озак вакытлы максатчан программасын раслау турында» 2011 ел, 22 сентябрь, 786 нчы карары белән расланган «2011-2015 елларга «Уңайлы мохит» Татарстан Республикасы озак вакытлы максатчан программасы нигезендә алып барылды» сүзләрен «алып барылды» сүзләренә алмаштырырга;

24 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$24^1$. Кадетларга белем бирүне үстерү»;

24 нче пунктның өченче абзацында «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Кадет мәктәбе һәм кадет интернат мәктәбе турында типлаштырылган нигезләмәне раслау хакында» 2010 ел, 15 февраль, 117 нче боерыгы белән расланган Кадет мәктәбе һәм кадет интернат мәктәбе турында типлаштырылган нигезләмә нигезендә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

«2014 – 2025 елларга өстәмә белем бирүне, инвалид балаларга белем бирүне кертеп, үстерү һәм бу өлкә хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында:

1 бүлектә:

уникенче абзацта «Балалар сәнгать мәктәпләрендә сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәр алды программаларын тормышка ашыруны беркетә торган «Мәгариф турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 17 июнендәге 145-ФЗ номерлы Федераль законны кабул итү мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә белем бирү кластерының уңышлы эшләве өчен шартлар тудырды.» сүзләрен «Балалар сәнгать мәктәпләрендә сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәр алды программаларын тормышка ашыру мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә белем бирү кластерының уңышлы эшләве өчен шартлар тудырды.» сүзләренә алмаштырырга;

кырык беренче абзацта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениесе турында типлаштырылган нигезләмәне раслау хакында» 1995 ел, 07 март, 233 нче карары белән (2009 ел, 10 март ред.) расланган Балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениесе турында типлаштырылган нигезләмә («III. Төп эшчәнлекләр» бүлеге, 27 п.) нигезендә дәресләр» сүзләрен «Дәресләр» сүзләренә алмаштырырга;

«2014 – 2025 елларга һөнәр белеме һәм югары уку йортларын тәмамлаганнан соң белем бирүне үстерү һәм бу өлкә хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында:

1 бүлектә:

унберенче – уникенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясенең милли иминлек стратегиясе (Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең милли иминлек стратегиясе турында» 2015 елның 31 декабрендәге 683 номерлы Указы белән расланган);

2017 – 2030 елларга Россия Федерациясендә мәгълүмати җәмгыятьне үстерү стратегиясе (Россия Федерациясе Президентының «2017 – 2030 елларга Россия Федерациясендә мәгълүмати җәмгыятьне үстерү стратегиясе турында» 2017 елның 9 маендагы 203 номерлы Указы белән расланган);»;

ундүртенче – уналтынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт яшьләр сәясәте нигезләре (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 ел, 29 ноябрь, б-2403 нче боерыгы белән расланды);

2013 – 2020 елларга «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2013 – 2020 елларга «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 15 апрель, 295 нче карары белән расланды);

«Социаль өлкә тармакларында мәгариф һәм фәннең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлтелгән үзгәрешләр» чаралар планы («юл картасы») (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 ел, 30 аперль, б-722 нче боерыгы белән расланды);»;

егерме икенче абзац үз көчен югалткан дип санарга;

егерме дүртенче абзац үз көчен югалткан дип санарга;

«Һөнәр белеме бирү системасы торышы» бүлекчәсендә:

унөченче абзацта «, ә аннары «Социаль өлкә тармакларында мәгариф һәм фәннең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлтелгән үзгәрешләр» чаралар планында («юл картасында») (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 ел, 30 аперль, б-722 нче боерыгы белән расланды) өстәмә тәгаенлау тапты» сүзләрен төшереп калдырырга;

егерме бишенче абзацта «Кама инновацион территориаль-җитештерү кластеры программасы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасын раслау турында» 2013 ел, 3 сентябрь, 624 нче карары белән расланган) яңа технологик чикләргә чыгуны һәм нефть химиясе һәм машина төзелеше продукциясенең яңа базарларында ныгуны күздә тота.» сүзләрен төшереп калдырырга;

егерме тугызынчы абзацта «2013 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 31 декабрь, 1193 нче карары белән расланган) нигезендә төзелештә» сүзләрен «Төзелештә» сүзенә алмаштырырга;

утызынчы абзацта «2013 – 2016 елларга Татарстан Республика-сының машина төзелеше һәм нефть химиясе комплекслары предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» программасы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 13 февраль, 99 нчы карары белән расланган) предприятиеләрнең кадрлар аудиты һәм өстенлекле юнәлешләр буенча кадрлар әзерләүнең турыдан-туры программаларын үз эченә алды. Программаның төп максатларының берсе – нефть химиясе һәм машина төзелеше предприятиеләрендә 17 мең югары җитештерүчәнлекле эш урыннары булдыру. Шулай итеп, җитештерү технологияләрен яңарту һәм фәнни тикшеренүләр нәтиҗәләрен гамәлгә кертү белән

бер рәттән хезмәткәрләрнең квалификацияләре үсү республика икътисадының төрле секторларын инновацион үстерү шарты сыйфатында карала.» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 бүлектә:

«Ярдәмче программаның төп чаралары тасвирнамәсе» бүлекчәсендә:

унберенче абзацта «2013 – 2020 елларга «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасында (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 ел, 15 апрель, 295 нче карары белән расланды), шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктның өченче абзацында:

икенче җөмләне төшереп калдырырга;

«Әлеге тәртип нигезендә тармак министрлыклары» сүзләрен «Тармак министрлыклары» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип санарга;

19 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19[1]. Һөнәри белем бирү оешмаларын норматив-җан башына финанслауны камилләштерү»;

19 пунктның икенче абзацында «, шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының һөнәри мәгариф системасында квалификацияле эшчеләр һәм белгечләр әзерләү күләмнәрен һәм профильләрен формалаштыру турында» 1999 ел, 31 декабрь, 887 нче карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы фәнни-белем бирү кластерларында квалификацияле эшчеләр һәм белгечләр әзерләүгә дәүләт заказын формалаштыру тәртибен раслау турында» 2012 ел, 6 апрель, 277 нче карары» сүзләрен төшереп калдырырга;

«2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында фәнне һәм фәнни тикшеренүләрне үстерү» ярдәмче программасында:

1 бүлектә:

«Илнең бердәм дәүләт фәнни-техник сәясәте кысаларында фәнни эзләнүләр белән идарә итү төбәк системасы роле һәм урыны» бүлекчәсендә «2009 елда кабул ителгән 2020 елга кадәр Россия Федерациясенең милли иминлеге стратегиясе» сүзләрен«Стратегик» сүзенә алмаштырырга;

асъюлда «[6] Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 24 гыйнвар, 38 нче карары белән расланган 2011-2013 елларга Татарстан Республикасының инновация меморандумы.» сүзләрен төшереп калдырырга;

«2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженер инфраструктураны үстерү» ярдәмче программасында:

2 бүлектә:

3 пунктның өченче абзацында «Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтү турында»,» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин